**Ноябрь аена сынамышлар**

Мартта күк күкрәсә, салкыннар көтегез.

Күк күкрәмичә генә яшен күрсәгез, җәй салкын булыр.

Март яңгырлы булса, гөмбәле җәйгә ишарә.

Мартта суык һәм коры булса, икмәк уңар.

Мартта боз сөңгеләре озын булса, яз озак килер.

Мартта томаннар еш төшсә, яңгырлы җәйгә.

Март ахырында карның тиз эрүе һәм суларның тиз китүе дә яңгырлы җәй билгесе.

**Көндәлек сынамышлар**

9 мартта кар яуса, апрель дә шундый ук булыр.

10 мартта ала каргалар тавышланса, җәй яңгырлы килер. Әгәр кара каргалар оя корса, тиздән һава торышы утырыр.

12 мартта – җылы яктан искән җил һәм тамчы таму – җылы җәйгә ишарә.

13 март көнне яңгыр яуса, җәй юеш килер.

23 март көнне ала карга томшыгын канат астына яшерсә, суыта.

24 мартта ала каргалар тавышланып йөрсә, һава торышы бозыла.

28 мартта акчарлаклар очып килсә, апрель җәй кебек булыр.

29 март нинди – апрель шундый.

30 мартта торналар килсә, кинәт җылыта.

Гөрләвекләр ага башласа, ташулар да озак көттермәс.

31 март кичендә йолдызлар гадәттәгедән ваграк күренсә – яңгырга.



**“ Әнием”**

Әни безнең бик оста,
Әмма сүзе бик кыска.
Төгәллекне ярата
Гел үзенә карата.

Көн дә иртүк тора ул,
Мал карый, безне карый
Йөздән елмаю китми
Беркем дә аңа җитми.

Без аның өч йолдызы
Елгадагы кондызы
Бик әйбәт егетләре
Киләчәк өметләре.

Бәйрәме җитә әнинең,
Нәрсә теләргә икән?
Тазалыкмы, саулыкмы?
Кояш гомере микән?

Дөньялар имин булсын.
Кояш гел көлеп торсын
Һәр сабый да йокыдан
Әни! – дип сикереп торсын!

Хайдаров Руслан

**Газетаны оештыручы һәм баш редактор**
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы
**Редколлегия әгъзасы:**
Мифтахетдинова Фирдания Ансар кызы

**Индекс-** 422020

**Адрес:** ТР, Арча муниципаль районы ,Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 йорт.

МБОУ «Ново-Кырлайская СОШ имени Г.Тукая»
МБГБУ «Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе»

Апрель ,2026
№ 8

# ЧИШМӘ БАШЫ

## Россиядә Халыклар бердәмлеге елын һәм Татарстанда хәрби һәм хезмәт батырлыгы елын ачу тантанасы

Бүген мәктәптә зур бәйрәм, Россиядә Халыклар бердәмлеге елын һәм Татарстанда хәрби һәм хезмәт батырлыгы елын ачу тантанасы булып узды. Фестиваль әлеге ике мөһим теманың әһәмиятен ассызыклау өчен менә дигән мөмкинлек булды. Без бердәмлек көче, бергә булу, бер-береңә ярдәм итү һәм уртак киләчәк төзүнең мөһимлеге турында сөйләштек. Фестивальдә Халыкара хатын-кызлар көне темасы аерым урын алды. Без, шатланып һәм горурланып, бәйрәмгә иң кадерле һәм иң яраткан кунакларыбызны – укучыларыбызның әниләрен чакырдык! Бу көн аларга үзләренең яратуларын, рәхмәтләрен һәм соклануларын белдерү өчен менә дигән сәбәп булды. Балалар күңелгә үтеп керерлек чыгышлар, җырлар, шигырьләр һәм биюләр әзерләделәр. Һәр номерда, чын гаилә бәйрәме атмосферасын тудырып, чын күңелдән наз һәм җылылык сизелә иде.



Мәктәптә бердәмлек һәм патриотизм рухы

# Мәктәптә бердәмлек һәм патриотизм рухы

18 март — Кырымның Россиягә кушылу көне уңаеннан, «Кырымның Россиягә кушылуы - Без бергә!» дип исемләнгән тематик класс сәгатьләре узды.

Балалар Кырым ярымутравының барлыкка килү тарихы, ярымутрауның география урыны һәм ландшафты, табигать һәм климаты, халкы һәм икътисады, милли кухнясы, Кырым һәм Севастопольнең истәлекле урыннары белән таныштылар.Шулай ук укучылар 2014 елның 18 мартында референдум үткәрелү , аның нәтиҗәсендә, «Кырым Республикасын Россия Федерациясенә кабул итү турында шартнамә» имзалануын белделәр.

Чара үткәнгә хөрмәт күрсәтү генә түгел, ә илнең киләчәге аның һәр гражданинына бәйле булуын искә төшерү дә. Һәркем үз тарихын истә тотарга, аның белән горурланырга һәм бу белемнәрне киләсе буыннарга тапшырырга тиеш. Шул рәвешле генә без илебезне көчле һәм бердәм итеп саклап кала алачакбыз.



## “Син Тукайны беләсеңме?”

Арчада Үзәк китапханәдә татар әдәбиятының иң якты йолдызы Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан, Арча районындагы Г.Тукай исемен йөрткән уку йортлары арасында “Син Тукайны беләсеңме?” дигән тема астында библиобрейн-ринг уздырылды. Интеллектуаль уенда безнең мәктәп укучылары да көч сынашты.Уен барышында укучылар 10 төрле бирем үтәп, төрле өлкәләрдә белем дәрәҗәләрен күрсәттеләр. Катнашучылар Тукайның балачагы белән бәйле әсәрләреннән өзекләр, иҗатын өйрәнгән белгечләр һәм Г.Тукай портретын ясаган рәссамнарны тануга биремнәр чиштеләр. Шулай ук уенда бөек шагыйрнең әсәрләренә ясалган иллюстрацияләрне кулланып, җанлы картина ясап, Г.Тукай шигырьләрен яттан сөйләү дә оештырылды..Әлеге чарада мәктәбебезнең "Г.Тукай оныклары" командасы икенче урынга лаек булды. Чын күңелдән котлыйбыз укучыларыбызны

!





# Укучыларыбызның уңышлары

Бүген мәктәбебезнең 8 сыйныф укучысы Минуллина Язилә (җитәкчесе Рәхимова Р.И. кызы) Республикакүләм «Великое слово «Победа», «Җиңү»-бөексүз», «The great word «Victory»» исемле фәнни-гамәли эзләну эшләре конференциясендә катнашты һәм II урынга лаек булды. Киләчәктә дә зур уңышлар телибез.



Мәктәбебезнең 5 класс укучысы Хайдаров Нур (җитәкчесе Мифтахова Г.Г.) "Тропой открытий В.И.Вернадского" исемле Бөтенроссия тикшеренү эшләре конкурсының региональ этабында 3 урынга лаек булды. Киләчәктә дә аңа зур уңышлар!



# Спорттагы уңышларыбыз

1 март көнне Байлар Сабасында 2009 нчы елгы һәм аннан яшьрәк егетләр арасында көрәш ярышлары булып узды.

Ярышта "Арча" спорт мәктәбеннән дә яшь көрәшчеләр катнашты һәм призерлар арасында безнең мәктәбебез укучысы да бар.

Ахметгалиев Данияр үз үлчәмендә (40 кг) 3 урынга лаек булды.

Даниярга һәм аның тренеры Саляхов Марат Радиковичка киләчәктә дә уңышлар һәм тагын да зуррак үрләр яулавларын телибез.

Призерларга медаль, грамота, акчалата бүләкләр тапшырылды.

Арча Спорт сараенда узган волейбол ярышында, 2014-15 елгылар арасында кызлар 2 урынны яуладылар. Тренерлары Әмиров Н. А. Кызларыбызны котлыйбыз.



"Сосна"ҖЧҖ призларына 2016 елда туган һәм аннан яшьрәк егетләр һәм кызлар арасында чаңгы узышлары буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы беренчелегендә 2 класс укучысы Хәйруллина Хадиджа 1 нче урынны яулады. Укучыбызны котлыйбыз! Алга таба да уңышлар телибез.






# Мәктәп тормышы

Мәктәп тормышы

**“Ашыт" дәүләт табигый тыюлыгы җитәкчеләре белән очрашу**

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты "Ашыт" дәүләт табигый тыюлыгы җитәкчесе Шәйхетдинов Илшат Шамил улы, белгечләре Әхмәтҗанов Рәшит Зиннур улы, Абдрахманова Гөлнара Ильяс кызы, Хурамшина Талия Тәлгат кызы, Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслары министрлыгының Төньяк территориаль идарәсе белгече Юсупжанова Гүзәл Рәҗәб кызы укытучылар белән бергәләп башлангыч классларда һәм 5,6 классларда очрашу үткәрделәр. Укучылар бик теләп викторина сорауларына җавап бирделәр, табигать обьектлары рәсемнәрен ясап, ул рәсемнәрне якладылар, үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар таптылар. Очрашу бик файдалы узды.



# Урманнар – безнең байлыгыбыз

21 март – Халыкара урманнар көне. Бу көнне 9нчы сыйныфта, сыйныф җитәкчеләре Шакирова Клара Даниловна җитәкчелегендә, "Урманнар – безнең байлыгыбыз" дигән темага багышланган кызыклы һәм файдалы класстан тыш чара үткәрелде. Чараның төп максаты – укучыларның урманнарга карата булган хисләрен, уй-фикерләрен уртаклашу, урманчы һөнәре белән таныштыру һәм урманнарны саклауның актуаль проблемаларына басым ясау иде.

Чара башында, К. Д. Шакирова урманнарның кеше тормышындагы әһәмиятен, аларның экологик, икътисади һәм рухи байлыгын ассызыклап, укучыларны бу бәйрәм белән котлады. Аннан соң, сәхнә укучыларның кулларына күчте. Һәркем урман турында үзенең уй-фикерләрен, хисләрен ачыктан-ачык белдерде. Кемдер урманны тынычлык, ял итү урыны дип атаса, икенчеләре аны табигатьнең үпкәсе, кояш нурларын җылытучы, суларны чистартучы дип билгеләп үтте. Укучылар урманнарның төрле хайваннар һәм үсемлекләр өчен нинди зур әһәмияткә ия булуын да искәрттеләр.

Чараның икенче өлеше урманчы һөнәренә багышланды. Укучылар бу һөнәрнең нинди җаваплы, катлаулы һәм шул ук вакытта бик кирәкле булуын аңлап алдылар. Алар урманчыларның урманнарны саклау, яңарту, агачларны утырту, аларны төрле зарарлы бөҗәкләрдән һәм янгыннардан саклау кебек эшләре турында сөйләделәр. Шулай ук, бу һөнәрне кайсы уку йортларында алырга мөмкинлеге хакында да мәгълүматлар яңгырады. Бу мәгълүматлар, һичшиксез, киләчәктә һөнәр сайлау алдында торучы укучылар өчен бик файдалы булды.

Чараның иң мөһим өлеше – урманнарны саклау проблемасына багышланды. Укучылар урманнарның кимүе, аларның юкка чыгуы сәбәпләре турында фикер алыштылар. Кеше эшчәнлеге, урманнарга ут төртү, агачларны рөхсәтсез кисү кебек факторларның урманнарга зур зыян китерүен аңлап алдылар. Бу актуаль проблеманы чишү юллары турында да актив фикер алышулар булды. Укучылар урманнарны саклау өчен һәркемнең үз өлешен кертә алуын, мәсәлән, агачларны утырту, чүп-чарны җыю, урманнарга ут төртмәү кебек гади, әмма бик мөһим эшләрне башкару аша бу проблеманы чишәргә ярдәм итә алуын ассызыкладылар.






# "Авылда юл йөрү кагыйдәләре" темасына чара

Мәктәбебездә башлангыч сыйныф укучылары катнашында "Авылда юл йөрү кагыйдәләре" темасына чара уздырылды. Әлеге мероприятиедә укучылар белән бергәттән ата-аналар да актив катнашты, алар арасында уен ярышлары оештырылды. Чарага Арча районы "Юл йөрү хәрәкәте иминлеге" профилактика бүлеге җитәкчесе Мөхәммәтҗанова Энҗе Газиз кызы да чакырылган иде. Ул балаларга һәм ата-аналарга юл йөрү кагыйдәләре турында мөһим мәгълүматлар бирде, юл хәрәкәтендә иминлек кагыйдәләрен үтәүнең әһәмиятен ассызыклады. Мероприятие бик файдалы һәм кызыклы узды, балалар һәм ата-аналар юл йөрү кагыйдәләрен яхшырак үзләштерде. Чара барышында укучыларга юл хәрәкәте билгеләре, светофор сигналлары, пешеходлар өчен куркынычсыз юл аркылы чыгу кагыйдәләре турында аңлатмалар бирелде. Шулай ук, уеннар һәм викториналар ярдәмендә балалар үз белемнәрен сынап карадылар, дөрес җаваплар өчен бүләкләр дә тапшырылды. Ата-аналар белән бергә үткәрелгән бу чара балаларның юлда үз-үзләрен тоту күнекмәләрен ныгытуга ярдәм итте, әти-әниләрнең дә юл хәрәкәте кагыйдәләренә карата җаваплылыгын арттырды.

Мөхәммәтҗанова Энҗе Газиз кызы үз чыгышында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүдә гаилә тәрбиясенең зур роль уйнавын билгеләп үтте. Ул ата-аналарга балалар белән юлда йөрү кагыйдәләрен даими рәвештә кабатлау, аларга үрнәк булу кирәклеген искәртте. Шулай ук, мәктәп һәм гаилә хезмәттәшлеген ныгыту юллары турында фикер алышу булды, киләчәктә мондый профилактик чараларны ешрак уздыру тәкъдим ителде.

Мероприятие ахырында балаларга һәм ата-аналарга юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә багышланган тематик буклетлар һәм мәгълүмати материаллар таратылды. Чараның нәтиҗәләре буенча, мәктәп коллективы киләчәктә дә шундый профилактик акцияләрне актив рәвештә үткәрүне дәвам итәргә ниятли, чөнки бу балаларның иминлеген тәэмин итүдә һәм юл хәрәкәте культурасын формалаштыруда зур әһәмияткә ия.

